**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Иске Сережкино торак пунктында

**16 октябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Сережкино торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 2900 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Иске Сережкино торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Иске Сережкино торак пунктында су башняларын, скважиналарны, чишмәләрне ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юллар төзү, проект-смета документациясе өчен түләү) Иске Сережкино торак пунктында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Иске Сережкино торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү, торак пункт урамнарын җәйге тоту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Иске Сережкино торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, паркларны, яр буйларын) төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, Югары Чегодай торак пунктында адрес такталарын ясау.

2. Әлеге карарны Иске Үтәмеш, Муса Җәлил урамы, 54 нче йорт, Урманасты Үтәмеш, Совет урамы, 12 нче йорт, Югары Чегодай, Совет урамы, 25 нче йорт, Иске Сережкино урамы, Степная 7а адресы буенча мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Утәмеш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов